**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 13 май № 314

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2010 ел, 24 август, 678 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2010 ел, 24 август, 678 нче карарына белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 8 октябрь, 790 нчы; 2010 ел, 3 декабрь, 987 нче; 2010 ел, 30 декабрь, 1175 нче; 2011 ел, 28 апрель, 347 нче; 2011 ел, 30 апрель, 356 нчы; 2011 ел, 25 июль, 576 нчы; 2011 ел, 19 август, 688 нче; 2011 ел, 19 сентябрь, 778 нче; 2012 ел, 20 гыйнвар, 31 нче; 2012 ел, 25 апрель, 323 нче; 2012 ел, 1 июнь, 464 нче; 2012 ел, 31 октябрь, 932 нче; 2012 ел, 31 декабрь, 1186 нчы; 2013 ел, 30 гыйнвар, 50 нче; 2013 ел, 29 апрель, 298 нче; 2013 ел, 29 июнь, 457 нче; 2013 ел, 26 август, 600 нче; 2013 ел, 26 октябрь, 796 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1105 нче; 2014 ел, 27 июнь, 443 нче; 2014 ел, 29 октябрь, 791 нче; 2015 ел, 20 февраль, 104 нче; 2015 ел, 10 март, 140 нчы; 2015 ел, 8 апрель, 230 нчы; 2015 ел, 16 май, 350 нче; 2015 ел, 14 август, 591 нче; 2015 ел, 25 ноябрь, 889 нчы; 2015 ел, 30 декабрь, 1031 нче, 2016 ел, 26 гыйнвар, 38 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 7 пунктында «яшьләр сәясәте учреждениеләре» сүзләрен «яшьләр сәясәте оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

2.4 пунктта «яшьләр сәясәте учреждениеләре» сүзләрен «яшьләр сәясәте

оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

2.5 пунктта «мәктәпкәчә учреждениеләр», «гомуми белем бирү учреждениеләре» сүзләрен «мәктәпкәчә белем бирү оешмалары», «гомуми белем бирү оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктта «яшьләр сәясәте учреждениеләре» сүзләрен «яшьләр сәясәте оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

4 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 4.2.9, 4.2.10 пунктлар өстәргә:

«4.2.9. Әлеге Нигезләмәнең 4.2.1 – 4.2.8 пунктларында күрсәтелмәгән хезмәткәрләргә, шул исәптән белем бирү оешмалары җитәкчеләренә, аларның урынбасарларына һәм структур бүлекчәләре җитәкчеләренә атнасына 40 сәгать озынлыктагы эш вакыты билгеләнә.

4.2.10. Эш хакы ставкасына укыту (педагогика) эше сәгатьләре нормасы түбәндәгечә билгеләнә:

физик тәрбия җитәкчеләренә, оештыручы укытучыларга (тормыш иминлеге нигезләре, армиягә чакыру алды әзерлеге) елына 360 сәгать күләмендә;

укучылары 50 дән артмаган санда башлангыч гомуми белем бирү оешмалары (педагогика көллиятләре студентлары педагогик практика үтү өчен беркетелгән башлангыч гомуми белем бирү оешмаларыннан тыш), укучылары 80 нән артмаган (шәһәрләрдә һәм шәһәр тибындагы поселокларда – 100 дән артмаган)санда кичке (сменалы) гомуми белем бирү оешмалары директорларына атнасына 10 сәгать күләмендә;

1 – 2 төркемле мәктәпкәчә белем бирү оешмалары мөдирләренә (балалар тәүлек әйләнәсе тора торган бер яки берничә төркемле оешмалардан тыш) көненә 3 сәгать күләмендә.»;

5 таблицага түбәндәге эчтәлекле 29-30 юллар өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «29. | Ишетү буенча, күрү буенча сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән, терәк-хәрәкәт аппаратында бозылулар булган, акылы зәгыйфь тәрбияләнүчеләр өчен җайлаштырылган белем бирү программаларын тормышка ашыра торган мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында (төркемнәрендә) эшләү | Беренче дәрәҗәдәге ярдәмче укытучы персоналы вазыйфасы | 1 | 9,0 |
| | | икенче дәрәҗәдәге ярдәмче укытучы персоналы вазыйфасы | 1 - 2 | 9,0 |
| | | педагогика хезмәткәрләре вазыйфасы | 1 - 4 | 9,0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 30. | Сөйләмнәрендә каты бозылулар булган тәрбияләүчеләр өчен җайлаштырылган белем бирү программаларын тормышка ашыра торган мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында (төркемнәрендә) эшләү | педагогика хезмәткәрләре вазыйфасы | 3 | 6,0»; |

9 бүлекнең 9.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.2. Белем бирү оешмалары һәм яшьләр сәясәте оешмалары җитәкчеләренең вазыйфаи хезмәт хакы җитәкчегә вазыйфаи хезмәт хакы билгеләнгән ел алдыннан булган елның 1 гыйнварына төп персоналны тарификацияләү нигезендә, хезмәт шартнамәсе нигезендә ул җитәкләгән оешманың төп персоналына караган хезмәткәрләрнең уртача эш хакына мөнәсәбәттә ике тапкыр күберәк итеп оешманың гамәлгә куючысы тарафыннан елга бер тапкыр билгеләнә. Җитәкченең хезмәт хакын исәпләгәндә хезмәт хаклары (вазыйфаи хезмәт хаклары) аудиториядән тыш мәшгульлек һәм хезмәткәрләрнең (персоналның) стимул бирү һәм компенсация характерындагы аерым төр түләүләре исәпкә алына.»;

14 һәм 15 таблицалар исемендә тиешле килешләрдәге «яшьләр сәясәте учреждениеләре» сүзләрен тиешле килешләрдәге «яшьләр сәясәте оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

11.4 пунктта «яшьләр сәясәте учреждениеләре» сүзләрен «яшьләр сәясәте оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

2.4 һәм 2.5 пунктларда «яшьләр сәясәте учреждениеләре» сүзләрен «яшьләр сәясәте оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

4.1 һәм 6.4 пунктларда «эш хакының нигез ставкасы (нигез хезмәт хакы) өчен сәгатьләр нормасы» сүзләрен «эш вакыты озынлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

5.22 пунктта «яшьләр сәясәте учреждениеләре» сүзләрен «яшьләр сәясәте оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларының физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

2.4 һәм 2.5 пунктларда «яшьләр сәясәте учреждениеләре» сүзләрен «яшьләр сәясәте оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

6.3 пунктта «эш хакының нигез ставкасы (нигез хезмәт хакы) өчен сәгатьләр нормасы» сүзләрен «эш вакыты озынлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

8 бүлекнең 8.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.2. Белем бирү оешмалары һәм яшьләр сәясәте оешмалары җитәкчеләренең вазыйфаи хезмәт хакы җитәкчегә вазыйфаи хезмәт хакы билгеләнгән ел алдыннан булган елның 1 гыйнварына төп персоналны тарификацияләү нигезендә, хезмәт

шартнамәсе нигезендә ул җитәкләгән оешманың төп персоналына караган хезмәткәрләрнең уртача эш хакына мөнәсәбәттә ике тапкыр күберәк итеп оешманың гамәлгә куючысы тарафыннан елга бер тапкыр билгеләнә. Җитәкченең хезмәт хакын исәпләгәндә хезмәт хаклары (вазыйфаи хезмәт хаклары) аудиториядән тыш мәшгульлек һәм хезмәткәрләрнең (персоналның) стимул бирү һәм компенсация характерындагы аерым төр түләүләре исәпкә алына.»;

10.5 пунктта «яшьләр сәясәте учреждениеләре» сүзләрен «яшьләр сәясәте оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренең медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

2.4 һәм 2.5 пунктларда «яшьләр сәясәте учреждениеләре» сүзләрен «яшьләр сәясәте оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

4.1 һәм 6.4 пунктларда «эш хакының нигез ставкасы (нигез хезмәт хакы) өчен сәгатьләр нормасы» сүзләрен «эш вакыты озынлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

5.23 пунктта «яшьләр сәясәте учреждениеләре» сүзләрен «яшьләр сәясәте оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының югары белемнең дәүләт белем бирү оешмалары һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

4.1 пунктта «Педагогика хезмәткәрләренең эш вакыты озынлыгы (эш хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләре нормасы) турында» 2010 ел, 24 декабрь, 2075 нче» сүзләрен «Педагогика хезмәткәрләренең эш вакыты озынлыгы (эш хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләре нормасы) турында һәм хезмәт шартнамәсендә әйтелгән педагогика хезмәткәрләренең укыту йөкләмәсен билгеләү тәртибе хакында» 2014 ел, 22 декабрь, 1601 нче» сүзләренә алмаштырырга;

7.3 пунктта «эш хакының нигез ставкасы (нигез хезмәт хакы) өчен сәгатьләр нормасы» сүзләрен «эш вакыты озынлыгы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карарның гамәле 2016 елның1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков